ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/12

Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милегендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алынган күчемсез милекне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 159-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/8, 2015 елның 09 ноябрендәге № 3/5, 2017 елның 24 октябрендәге 20/6, 2018 елның 10 августындагы 26/10 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә

1) 1 пунктта «ачык» сүзен төшереп калдырырга;

2) 3 пунктның 7 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

7) муниципаль унитар предприятиеләрне үзгәрткәндә муниципаль милекне коммерцияле булмаган оешмага һәм муниципаль милекне дәүләт корпорацияләренә һәм башка коммерцияле булмаган оешмаларга муниципаль берәмлекнең мөлкәти взносы сыйфатында тапшырганда»;

3) 14 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә :

«14. Кече һәм урта эшмәкәрлек субьектларына арендага бирелгән муниципаль милекне хосусыйлаштыру фараз планына (программасына)

кертү хакында карар кабул иткәндә, 2008 елның 22 июлендәге «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милегендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алынган күчемсез милекне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 159-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, аларның мондый мөлкәтне алганда өстенлекле хокукы исәпкә алыныла.»;

4) 15 пунктта «,бәяләү объектын бәяләү турындагы хисап төзелгән көннән алып «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта муниципаль милекне сату турында хәбәр урнаштырылган көнгә кадәр алты айдан да артмаган очракта» сүзләрен өстәргә;

5) 21 пунктның 6 пунктчасын гамәлдән чыккан дип танырга;

6) 28 пунктта «, нәтиҗәләре хакында мәгълүмат» сүзләрен «һәм аның нәтиҗәләре хакында» сүзләренә алыштырырга;

7) 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль милекне сату хакында һәм сату нәтиҗәләре турында мәгълүмат Яр Чаллы шәһәренең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында һәм Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге Россия Федерациясе Хөкүмәте аукционнар турында мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләгән рәсми сайтында урнаштырыла.

Муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар «Интернет» челтәрендәге һәркем өчен керү мөмкинлеге булган рәсми сайтта әлеге карар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә урнаштырыла.

Муниципаль милекне сату турында мәгълүмат, хосусыйлаштыру турында Федераль закон белән башкача билгеләнмәгән очракта, әлеге мөлкәтне сату гамәлгә ашырыласы көнгә кадәр утыз көннән дә ким булмаган вакыт эчендә урнаштырыла һәм хосусыйлаштыру турында Федераль законда каралган очраклардан тыш, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

1) мондый милекне хосусыйлаштыру шартлары турында карар кабул иткән җирле үзидарә органы исеме, әлеге карарның реквизитлары;

2) мондый милекнең исеме һәм аны индивидуализацияләргә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүматлар (милек характеристикалары);

3) мондый милекне хосусыйлаштыру ысулы;

4) мондый милекне сатуның башлангыч бәясе;

5) мондый милек бәясе турында тәкъдимнәр бирү формасы;

6) түләү шартлары һәм сроклары, кирәкле хисапларның реквизитлары;

7) задатка күләме, аны кертү вакыты һәм тәртибе, кирәкле хисап реквизитлары;

8) гаризалар, тәкъдимнәр бирү тәртибе, урыны, башлану һәм тәмамлану вакыты;

9) аукционда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документларның тулы исемлеге һәм аларны рәсмиләштерүгә таләпләр;

10) мондый милекне сату-алу килешүе төзү вакыты;

11) сатып алучыларны мондый милекне сату-алу килешүе шартлары һәм башка мәгълүмат белән таныштыру тәртибе;

12) аерым категория физик затларның һәм юридик затларның мондый милекне хосусыйлаштыруда катнашуын чикләү;

13) җиңүчеләрне (аукцион, махсуслаштырылган аукцион, конкурс уздырганда) яисә муниципаль милекне сатып алу хокукына ия затларны (аукцион үткәргәндә, аны сатканда, халык алдында тәкъдимнәр юлы белән һәм бәяне игълан итмичә генә) билгеләү тәртибе;

14) муниципаль милекне сатуга йомгак ясау урыны һәм вакыты.

15) мондый милекне сату буенча ел дәвамында игълан ителгән алдагы аукционнар турында һәм мондый милекне сату нәтиҗәләре турында мәгълүматлар.»;

- 9 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9) аукционда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документларның тулы исемлеге һәм аларны рәсмиләштерүгә таләпләр;»;

- түбәндәге эчтәлекле 15 пунктча белән тулыландырырга:

«15) мондый милекне сату буенча ел дәвамында игълан ителгән алдагы аукционнар һәм мондый милекне сату буенча аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүматлар.»;

8) 30 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 6 – 10 пунктчалар өстәргә:

«6) 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ санлы Федераль законның 10.1 маддәсе нигезендә хуҗалык ширкәтенең еллык бухгалтер (финанс) хисабы һәм хуҗалык ширкәтенең арадаш бухгалтер (финанс) хисабы урнаштырылган «Интернет» челтәрендәге сайт адресы;

7) хуҗалык җәмгыятенең күчемсез мөлкәте урнашкан җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре мәйданы;

8) хуҗалык җәмгыяте хезмәткәрләре саны;

9) хуҗалык җәмгыятенең күчемсез милек объектларының мәйданы һәм мондый объектларны хосусыйлаштырганда гамәлдә булган һәм билгеләнгән йөкләмә күрсәтелгән исемлек;

10) сату көненә кадәр бер ел эчендә мөлкәтне сату буенча алдагы аукционнар турында (аукцион булмау, аны оештырмау, гамәлдә түгел дип тану хакында) мәгълүматлар, сәбәпләрен (гаризалар булмау, бер сатып алучының гына килүе, башка сәбәп) күрсәтеп.»;

9) 31 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

10) 33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

«33. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта әлеге эшләрне башкарганнан соң ун көн эчендә урнаштырылырга тиеш.»;

11) 34 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34. «Интернет» челтәрендә сайтта урнаштырылырга тиешле муниципаль милекне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турындагы мәгълүматка түбәндәгеләр керә:

1) мондый милекне сатучының исеме;

2) мондый милекнең исеме һәм аны индивидуализацияләргә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүматлар (милек характеристикалары);

3) аукцион үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

4) хосусыйлаштыру алыш-биреш бәясе;

5) аукциондагы башка катнашучылар тәкъдимнәре белән чагыштырганда, мондый милек өчен иң югары бәяне тәкъдим иткән физик зат яисә юридик зат исеме, аукцион барышында мондый милекнең бәясе турында соңгы тәкъдим ясаган (бәяләр турында тәкъдимнәр бирүнең ачык рәвешеннән файдаланган очракта) аукциондагы җиңүченең яки аукцион барышында мондый милекнең бәясе турында соңгы тәкъдим алдыннан тәкъдим ясаган (бәяләр турында тәкъдимнәр бирүнең ябык формасын файдаланган очракта) аукционда катнашучының тәкъдименнән тыш;

6) аукцион җиңүчесе булган физик зат яки юридик зат исеме.»;

12) 40 пунктта «сатып алучыга читләштерү белән бергә» сүзләрен «сатып алучыга читләштерү» сүзләренә алыштырырга;

13) 14 бүлек исемен түбәндәгечә бәян итәргә:

«14 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ МИЛЕК ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ТӘРТИБЕ»;

14) 66 пунктта «сату турында игъланнар урнаштыру» сүзләрен «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта сату турында игъланнар урнаштыру» сүзләренә алыштырырга;

15) 72 пунктта «өченче – бишенче» сүзләрен «өченче, дүртенче» сүзләренә алыштырырга;

16) 74 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«74. Муниципаль милекне электрон формада сату (алга таба - электрон формада сату) электрон мәйданчыкта электрон мәйданчык операторы тарафыннан башкарыла.»;

17) 75, 76 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

18) 77 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«77. Электрон формада сату үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру әлеге Нигезнамәнең 7 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

«Интернет» челтәрендәге сайтта урнаштырылучы электрон формада сатуны үткәрү турында мәгълүматта әлеге Нигезнамәнең 7 бүлегендә каралган белешмәләр белән беррәттән электрон формада сату уздырылачак электрон мәйданчык, электрон мәйданчыкта теркәлү тәртибе, электрон формада сату үткәрү кагыйдәләре, аны үткәрү датасы һәм вакыты күрсәтелә.»;

19) 78 пунктта ««Интернет» челтәрендәге сайтта» сүзләрен «электрон мәйданчыкта» сүзләренә алыштырырга;

20) 80 – 82 пунктларны гамәлдән чыккан дип танырга;

2. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев